
БУГУЛЬМА
1781

# Син дә татарча сөйләш!

Средняя общеобразовательная школа № 6 города Бугульмы Республики Татарстан

мин татарча сөйләшәм!

**ФЕВРАЛЬ, 2018**



- **Фәнис Яруллин**
- **Бер күрешү – үзе бер гомер**
- **Муса Җәлил**
- **«Салют, сиңа Муса Җәлил»**
- ***21 февраль – халыкара туган тел көне**
- **АКЦИЯ БАШЛАНА…**
- **Егет солтаны -2018**

# Фәнис Яруллин



Фәнис Яруллин 1938 елның 9 февралендә Татарстан АССРның Баулы районы Кызылъяр авылында игенче гаиләсендә туган. Җидееллык белемне туган авылында ала, сигезенче сыйныфын Баулы урта мәктәбендә тәмамлый. 1954 елда «Татнефть» берләшмәсенең Баулы элемтә конторасында монтер булып эшли башлый.1957 елда Совет Армиясе сафларына чакырыла. Армиядә һава укчы радистлар мәктәбендә укый, спорт белән мавыга. Спорт күнегүләренең берсендә турниктан егылып, имгәнеп, гомерлеккә йөри алмас хәлдә кала.

Озак еллар урын өстендә яки хастаханәләрдә дәваланып ятуына карамастан, Фәнис Яруллин бөтен тырышлыгын, рухи көчен үзенең белем дәрәҗәсен күтәрүгә, әдәби иҗат эшенең серләрен үзләштерүгә юнәлтә: 1963 елда экстерн тәртибендә урта мәктәп программасы буенча имтихан тота, 1970 елда исә, читтән торып укып,Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлый. Шул елларда шигырьләр, хикәяләр язарга керешә. Матбугатта аның беренче әдәби иҗат тәҗрибәләре 1960 елда Баулы район газетасында, аннан соң республиканың үзәк газета-журналларында басылалар. 1964 елда авторның беренче мөстәкыйль китабы — «Мин тормышны яратам» исемле шигырьләр җыентыгы дөнья күрә. Аннан соң, алтмышынчы еллар дәвамында, мәктәп балаларына һәм яшүсмерләргә багышлап язылган тагын берничә хикәя һәм шигырь җыентыгы басылып чыга.



Җитмешенче еллар башында Фәнис Яруллин үзенең каләм көчен проза жанрының олырак формаларында да сынап карый. 1971 елда ул темасы бүгенге яшьләр тормышыннан алынып, сюжет нигезен автобиографик материаллар тәшкил иткән «Җилкәннәр җилдә сынала» исемле повестен тәмамлый. Әсәр «Казан утлары» журналында һәм Татарстан китап нәшриятында аерым китап булып басылып чыккач, аны әдәби җәмәгатьчелек тә, укучылар да хуплап каршы алалар. Бу повесте белән Фәнис Яруллин киң масса укучылар алдында таныла, әсәр русчага, казакъчага тәрҗемә ителә.

Фәнис Яруллин — ике дистәгә якын шигырь һәм проза китаплары авторы.1978 елда «Аерылмас дустым» һәм «Сулыш» шигъри җыентыклары өчен автор Татарстанның Муса Җәлил исемендәге комсомол премиясенә булды. Аның «Әнә килә автомобиль» комедиясе Г.Камал исемендәге татар дәүләт академия театры сәхнәсенә менеп, берничә сезон рәттән өзлексез уйналып килде һәм тамашачыларда уңыш казанды.

Фәнис Яруллин аеруча хикәя жанрында уңышлы эшли. Анын үзенчәлекле юмор белән сугарылган, тормышчан, заманча, оптимистик хикәяләре «һәркемнең үз сукмагы» дигән чираттагы җыентыгына тупланган, Әдипнең поэтик иҗатыннан аерым үрнәкләр рус теленә тәрҗемә ителеп, «Современник», «Аврора», «Волга», «Байкал» кебек журналларда һәм «Литературная Россия», «Комсомольская правда» кебек үзәк газеталарда да урын ала килә.

Язучы 2011 елның 8 декабрендә Казан шәһәрендә вафат була.

*Википедия — свободная энциклопедия*



# Бер күрешү – үзе бер гомер

***Тормышка мәхәббәт, яшәү көче, батырлык турында гүзәл әсәрләр иҗат итүче язучылар шактый. Корычтай ихтыярлы, рухи көчен кешеләргә үрнәк итеп куя алган шәхесебез Фәниç Яруллинны яратмаган, белмәгән кеше юктыр. Балаларны әкиятләре белән тәрбияләсә, өлкәннәрне үзенең әсәрләре белән уйландыра ул.***

***Чын күңеле белән тормышка гашыйк, дөньяны сөюче Фәнис абый белән күрешеп булмады, әмма бертуган апасы – Әнисә апа белән очрашырга насыйп булды безгә – 6 нчы мәктәпнең татар теле укытучыларына. Ул Бөгелмәдә гомер итә.***





Мөлаем, җитез апа безне шатланып каршы алды. Бусагадан керү белән өйдәге нур күңелләребезне җәлеп итте. Тугызынчы дистәне ваклаучы Әнисә апа уңганлыгы, җор телле булуы, кунакчыллыгы белән һәммәбезне сокландырды. Фәнис абый яраткан тәбикмәк белән сыйлады үзебезне. Ул энесе турында китап-журналларда булмаган кызыклы вакыйгалар турында сөйләде. Әнисә апа руслашкан шәһәрдә яшәвенә карамастан, шулкадәр чиста, саф татарча сөйләве белән безне таң калдырды.


Фәнис абый турындагы белемнәребез тагын да артты. Балачаклары авыр тормышта үтсә дә, алар шат күңелле, уңган булып үскәннәр. Фәнис абыйдан өлкәнрәк булса да, алар бер класста, бер парта артында утырганнар. "Безнең Фәнис бик җитез, үзсүзле, үз дигәненә ирешә торган иде. Әни кушкан эшне иң беренче булып башкарып чыга да, безгә булыша иде", – дип искә алды Әнисә апа. Ул туганын сагынуы, аның белән аралашу җитмәве турында әйтте. Баулы шәһәрендәге Фәнис Яруллин һәм аның хатыны Нурсөя апага куелган һәйкәл, Кызылъяр авылындагы музей булуы турында да зур горурлык белән сөйләде.

Нинди генә әсәре турында искә төшерә башласак та, Әнисә апа әсәрнең исемен дә, әсәр геройларын да атап барды. Берничә шигырен сөйләп күрсәтте. Ә менә бу шигырь сезнең турында дип, Фәнис абыйның "Иң гүзәл кеше икәнсез" дигән шигырен яттан укыды. Әдип язган китаплар Әнисә апаның өй түрендә урын алган. Без шул китап киштәсендәге китаплар, фотоальбомнар аша Фәнис абыйның рухын тойдык. Ул безгә: "Җиңәргә өйрән! Көчле рухлылар гына максатларына ирешә ала", – дигән кебек булды.

"Фәнис энем туган телен бик нык яратты, татар телен яратучыларга да зур ихтирам белән карады. Туганымның иҗатын кызыксынып өйрәнүчеләр булганда, телебез югалмас", – дип сүзен тәгәлләде Әнисә апа.

**Гөлназ ХАҖИПОВА,**
**6 нчы урта мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы.**
**Алсу Шаталова фотолары.**





# Муса Җәлил

*Муса Җәлил безнең йөрәкләрдә.*
*Батыр үлә,үлмәс ат алып,*
*Батырлыклар белән макталып,*
*Исемең калсын, үзең үлсәң дә,*
*Тарихларда укып ятларлык...*

Муса Җәлил исемен ишетүгә, тәүге булып уйга батырлык сүзе килә.Ялкынлы шигырьләр авторы, ватаныбыз азатлыгы өчен көрәшкән кыю солдат ул.Патриот шагыйрь фашист тоткынлыгына эләгеп тә рухи ныклыгын югалтмый, курку белмичә дошманга каршы көрәш алып бара.

Бөек Ватан сугышы башлангач,Муса Җәлил ,беренчеләрдән булып,сугышка китә. Ләкин 1942елның июнендә шагыйрь Волхов фронтында каты сугышлар вакытында яралы хәлендә дошман капканына эләгә.

Шагыйрь әсирлектә дә көрәшне туктатмый. Яшерен оешмага керә,ипәшләренең рухын күтәрә, аларны да көрәшкә өнди. Муса Җәлил әсирләр белән лагерьдан качып , партизаннарга барып кушылырга ниятли.Әмма бер хыянәтче аларның серләрен фашистларга хәбәр итә. Шуннан соң Җәлилне һәм аның иптәшләрен Мобиат төрмәсенә ябалар.

1944 елның февралендә фашистлар Муса Җәлилне һәм аның көрәштәшләрен үлем җәзасына хөкем итәләр.Егерме бишенче августа Плетцензее төрмәсендә унбер җәлилченең гомере өзелә.

Төрмәдә дә, җәзаны көткән чакта, шагыйрь фашистларга көчле нәфрәтен белдергән шигырьләр иҗат итә һәм аларны үзе ясаган кечкенә дәфтәрләргә язып бара.Җәлилнең әсирлектә язылган шигырьләре бөтен дөньга “Мобиат дәфтәре” дип танылды.

Бу дәфтәрне Габбас Шәрипов һәм Бельгия партизаны Андре Тиммерманс илебезгә кайтарып ташладылар.

Муса Җәлилнең исемен халкыбыз мәңгеләштерде. Казандагы Татар дәүләт опера һәм балет театры Муса Җәлил исемен йөртә. Шагыйрьгә Казанда һәйкәл куелды.

Шагыйрьнең һәм аның иптәшләренең батырлыгы безнең йөрәкләрдә мәңге яшәр, чөнки тарихыбызны,илебез азатлыгы өчен көрәшкән батырларыбызны онытырга хакыбыз юк. Дәхшәтле сугыш еллары турында хатирәләрне, истәлекләрне киләчәк буыннар да белергә тиеш.

*Новый поселогы урта мәктәбе 5 сыйныфы укучысы Гыйльфанов Булат Рафик улы*










# *«Салют, сиңа Муса Җәлил»*

*15нче февраль көнне 6нчы мәктәп укучылары өчен герой-шагыйрь Муса Җәлилгә багышланган «Салют, сиңа Муса Җәлил» дип исемләнгән шигырь бәйрәме оештырылды.*

*Балалар шагыйрьнең шигырьләре буенча рәсемнәр ясап килгәннәр иде. Аларның рәсемнәреннән, Муса Җәлилнең китапларыннан, журналдагы мәкаләләрдән күргәзмә төзелде.*

*Бәйрәм балаларның Муса Җәлил сүзләренә язылган «Кызыл ромашка» шигыре белән башланып китте. Алып баручылар балаларга Муса Җәлилнең шагыйрь генә түгел, ә сугышчы да, көрәшче дә булуы турында сөйләде. Экранда шагыйрьнең тормыш юлына багышланган презентация күрсәтелде. Балалар Муса Җәлилнең бик күп шигырьләрен яттан сөйләделәр. Бәйрәм күңелле үтте.*

*Герой-шагыйрь Муса Җәлилнең юбилеена багышланган шигырь бәйрәмебез балаларда шагыйрьгә карата ихтирам, горурлык хисләре тудырды.*

*Вәлиуллина Алинә.*

# 21 ФЕВРАЛЬ – ХАЛЫКАРА ТУГАН ТЕЛ КӨНЕ

“Халыкның иң зур байлыгы, иң кадерле рухи хәзинәсе, − һичшиксез, аның теле. Халык үзенең телен, оста бакчачы кебек, яман җилләрдән, рәхимсез салкыннар куырудан саклап, мең еллар буена үстереп килгән. Өзлексез баетып, матурлап, иң тирән фикерләрен, иң нечкә хисләрен дә аңлатып бирер дәрәҗәгә китергән”-дигән татар әдибе Г. Бәширов.

Татар теле – ЮНЕСКО тарафыннан бөтендөнья халыкара аралашу теле дип саналган 14 телнең берсе. Бу – туган телебез белән горурланырлык мөһим фактор.

Чөнки кечкенәдән өйрәтелгән туган тел халык йөрәген шигърият белән генә сугарып калмый, аның күңелендә милли горурлык хисләре дә уята, ата-бабаларыбыз теленнән рухи ләззәт алу мөмкинлеге бирә.

Бу хәл Пакистанда 1952 нче елның 21 нче февралендә була. Бангл теленә дәүләт статусы бирүне таләп итеп чыгыш ясаган биш студент үтерелә. Шушы вакыйгадан соң 47 ел үткәч, 1999 нчы елда, 21 нче февраль Бангладеш тәкъдиме белән, ЮНЕСКО тарафыннан Халыкара туган тел көне дип игълан ителә.



# АКЦИЯ БАШЛАНА…

**«Мин татарча сөйләшәм» акциясе** — һәр ел Татарстанда һәм татар дөньясында уза торган акция. Гадәттә, төп чаралар апрель аенда уза. Акция оештыручылары — Үзебез яңа буын хәрәкәте һәм Бөтендөнья татар яшьләре форумы. Акциягә Татарстан Министрлар кабинеты, Казан мэриясе, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, Бөтендөнья татар конгрессытеләктәшлек белдерә.

Акциянең төп максаты — шәһәр мохитендә татар теленең кулланыш даирәсен киңәйтү, шәһәрдә яңа татар мәдәниятын формалаштыру эшендә ярдәм итү. Беренче тапкыр «Мин татарча сөйләшәм» 2006 елда киләчәктә «Үзебез» хәрәкәтенә берләшәчәк яшь татар галимнәре, иҗади яшьләр тарафыннан уздырылган. Акция татар телнен кулланылышын популярлаштыруга юнәлгән иң үзенчәлекле һәм халыкта зур кызыксыну уяткан чараларның берсе. Әлегә ул бердәнбер гражданлык инициативасы күрсәткече булып тора.

Концерт

Акциянең төп чарасы — 26 апрель көнне Бауман урамында уза торган концерт. Биредә яңа агым музыкасы вәкилләре, яшь шагыйрьләр чыгыш ясый, төрле бәйгеләр оештырыла, «Синең беренче 150 татар сүзең» сүзлекләре, акция логотиплары төшерелгән футболкалар, түштамгалар таратыла.

Татар-дозор

2010 елда акция кысаларында беренче тапкыр "Татар-дозор" уены оештырылды. Биредә 6-10 кешелек дистәгә якын команда катнаша. Берничә сәгать эчендә алар 5 биремне үтәргә тиеш. Мәсәлән биремнәр арасында халыкны татарча сөйләштерү, кибетләрдә татар телен куллану белән танышу, транспортта Казан турында сөйләү, Бауманда татарча биергә өйрәтү кебек чаралар бар. Иң яхшы командаларга бүләкләр тапшырыла.

2011 елда Татар-дозорның спонсоры булып Билайн катнашты.

Интернет татарча сөйләшә

2011 елда «Мин татарча сөйләшәм» кысаларында «Интернет татарча сөйләшә» чарасы да уздырыла башлады. Акциянең максаты — кулланучылар арасында Интернетта татарча аралашуны популярлаштыру.

мин татарча сөйләшәм!

Ә син татарча сөйләшәсеңме?

Әйдә татарча сөйләшик!

# Егет солтаны -2018

Инде матур традициягә әверелде, елның-елында Татар мәдәният үзәгендә “Егет солтаны” дип исемләнгән бәйге үткәрелә. Анда мәктәпләрдә белем алучы югары сыйныф укучылары катнашып, үзара көч сынаша. Быел әлеге күркәм чара 21 февраль көнне узды.

Чараны алып баручы Эдуард Гафиятуллин бәйгенең шартларын җиткерде. Аннан соң жюри әгъзалары белән таныштырды. Шуннан егетләр беренче биремне үтәргә керештеләр. Бирем “Таныш булыйк” дип исемләнеп, ярышучылар тулы һәм кызыклы итеп үзләрен, гаиләләрен, укыган мәктәпләрен, хоббиларын тамашачыга тәкъдир итәргә тиеш булдылар. Конкурста катнашкан җиде егет тә бу биремне уңышлы башкарып чыкты. Икенче өлештә исә егетләр автомат сүтеп-җыюда ярыштылар. Монысында инде балларның күбрәге әлеге коралны кем тизрәк сүтеп җыйган, шуңа куелды. Аннан соң егетләр иҗади осталыкларын тәкъдим иттеләр: кайсы җырлады, кайсы биеде, музыка уен коралларында уйнады, кем нәрсәгә маһир, шуны күрсәтте. Дүртенче номинациядә Ватан тарихыннан сораулар бирелде, аларга дөрес җавап тапканнарга баллар өстәлә барды. Шулай итеп, мавыктыргыч бәйге узды да китте.

Ярышта катнашучыларга Дипломнар һәм истәлеккә бүләкләр тапшырылды.












**Пустовгар Данила, 9 В сыйныфы укучысы**

Бөгелмә шәһәре Татарстан Республикасы
муниципаль гомуми белем бирү учреждениесе
аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче
6нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе

8нче В сыйныфы укучылары һәм
туган тел һәм әдәбияты укытучылары

*Бәйрәм бүген, бәйрәм! – диеп,*
*Бар дөнья балкып торсын.*
*Әти бәйрәме икәнне*
*Әни дә белеп торсын,*
*Әни дә көлеп торсын.*
*Бүген бәйрәм көнендә*
*Әтиләрне котлыйбыз.*
*Шатлык, бәхет, сәламәтлек*
*Һәммәгезгә телибез,*
*– дип яза Зәкия Туфайлова үзенең*
*“Әти дә көлеп торсын” шигырендә.*

***Чыннан да, ир-егетләр, әтиләр бәйрәме шул ул – Ватанны саклаучылар көне.***

***23нче февраль - Ватанны саклаучылар көне. Бу батырлар һәм кыюлар көне. Безнең тыныч тормышыбызны дошман бозмасын өчен батыр ир-егетләребез илебез чикләрен саклыйлар. Бу бәйрәм берничә төрле исем белән йөртелде:- Совет Армиясе көне ; - Кызыл Армиянең туган көне;- Кораллы көчләр һәм Хәрби Диңгез флоты көне. Хәзер бу бәйрәм Ватанны саклаучылар көне дип йөртелә…***

